**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«03» 09 2020 ел Яр Чаллы № 3395

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 21 ноябрендәге «Тукай муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру турында» 5122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Тукай муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балансланган кайнар аш белән тәэмин итү максатында, «Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 1 мартындагы 47-ФЗ номерлы Федераль законны һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 37 статьясын үтәү йөзеннән, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 21 ноябрендәге «Тукай муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру турында» 5122 номерлы карарының 1 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1. Дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучылар мондый оешмаларны гамәлгә куючылар тарафыннан федераль бюджетның, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының, җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре һәм Россия Федерациясе законнарында каралган башка финанс чыганаклары хисабына көнгә кимендә бер тапкыр, кайнар эчемлекне санамыйча, кайнар ризык булуны күздә тоткан бушлай кайнар аш белән тәэмин ителәләр.

1.2. Тукай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч белем бирү программалары буенча белем алучы балаларны 51 сум 85 тиенлек түләүсез кайнар төшке аш белән тәэмин итәргә.

1.3. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә 5-11 сыйныф укучылары өчен

көненә 41 сум 70 тиен күләмендә кайнар аш белән тәэмин итүне оештырырга.

1.4. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә 5-11 сыйныф укучыларын кайнар аш белән тәэмин итү өчен ата-аналар түләвенең суммасы 34 сум 00 тиен.».

2. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Н.С. Габдуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.Р. Хәбибуллин